КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 43

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү өлкәсендәге чараларны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 25 декабрь, 1221 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү өлкәсендәге чараларны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 25 декабрь, 1221 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Уңайлы мохит» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 29 март, 363 нче карары белән расланган «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасына 7 нче кушымтада китерелгән Инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре тормышының өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм аларны бүлү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

Инвалидларга һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәренә тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә өстенлекле объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә үтемлелекне тәэмин итү өлкәсендәге чараларны финанс белән тәэмин итү тәртибендә:

1 пунктта «2014 – 2018 елларга» сүзләрен «2014 – 2020 елларга» сүзләренә алмаштырырга, «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «6 нчы һәм 7 нче кушымталар» сүзләрен «10 нчы һәм 11 нче кушымталар» сүзләренә, «2017 елның 13 декабрендәге 232н номерлы» сүзләрен «2018 елның 14 декабрендәге 269н номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин